**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

№ 199-р 1 апрель 2015 ел

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына әзерлек һәм бәйрәм итү буенча чаралар үткәрү турында

Нурлат муниципаль районы Башлыгының "1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына әзерлек һәм бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү турында" 18.09.2013 ел, №114 карарын үтәү максатларында һәм җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, предприятие, учреждение һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү максатларында:

1. 1 майдан 9 майга кадәр Нурлат муниципаль районында һәм Нурлат шәһәрендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына багышланган тантаналы чаралар үткәрергә.

2. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планын расларга (1 нче кушымта).

3. Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарларына, мәгариф, социаль-мәдәни үсеш буенча җитәкче урынбасарына, Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан музейларны, хәрби каберлекләрне, мемориалларны һәм һәйкәлләрне тәртипкә китерү эшен оештырырга.

4. Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары:

- 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итү кысаларында бәйрәм чаралары оештырырга;

- Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына «җиңел автомобильне иң яхшы бизәү " район конкурсын оештыру һәм үткәрү (3 нче кушымта).

5. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигына спорт чаралары оештырырга.

6. Нурлат муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Рәисенә бәйрәм чараларын тиешле статьялар буенча район бюджетында каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәкъдим итәргә.

7. Массакүләм мәгълүмат чараларында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын яктыртучы истәлекле рубрикалар, шул вакыйгаларда

катнашучыларның шәхси хатирәләрен бастырып чыгаруны, шулай ук чараларны яктыртуны оештырырга.

8. Нурлат муниципаль районының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә медицина күрсәтмәләре булган очракта шифаханә-курорт дәвалавына юллама бирү өлешендә Социаль хезмәт алудан баш тартмаган 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм анда катнашучыларга беренче чиратта шифаханә-курорт дәвалавы буенча эш оештырырга тәкъдим итәргә.

9. «Кадерле ветераныбыз» республика социаль-гуманитар проектын (2 нче кушымта)гамәлгә ашыру максатларында Сәламәтлек саклау оешмаларында Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен палаталарга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын һәм Нурлат шәһәре Советы депутатларын беркетү.

10. Предприятие, оешма, учреждение, иҗтимагый берләшмә җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына һәм ТР Хәрби комиссариатының Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы бүлегенә тәкъдим итәргә:

- 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итүгә әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга;

- Бөек Ватан сугышы ветераннарының, тыл хезмәтчәннәренең социаль-икътисади хәлен яхшырту һәм аларга өстәмә ярдәм күрсәтү, шул исәптән тормышның көнкүреш шартларын яхшырту буенча чаралар күрү.

11. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль – мәдәни үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин